**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР № 9**

Кәрәкәшле ав. 24 апрель 2024 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советының 2023 елның 31 маендагы «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында»гы 9 санлы карарына өстәмәләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль Закон, Федераль салым хезмәтенең 2022 елның 30 ноябрендәге «Түләтүгә өметсез дип танылган бурычны исәптән чыгару тәртибен һәм түләтүгә бурычны тану шартларын раслаучы документлар исемлеген раслау турында»гы ЕД-7-8/1131 санлы боерыгына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советының 2023 елның 31 маендагы «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында»гы 9 санлы карарына (алга таба - Карар) түбәндәге өстәмәләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 пункты түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырылырга:

- Россия Федерациясе Салым кодексының 48 маддәсендә билгеләнгән җәза вакыты тәмамланганнан соң, 500 сумнан артмаган бурыч суммасы белән физик затларның җир салымы һәм мөлкәтенә салым буенча.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ электрон адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм «Рәсми Татарстан» порталын мәгълүмати яктан урнаштырырга-«Интернет» телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ электрон адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар аның игълан ителүеннән соң бер ай узгач кына үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы А.Г.Дәүләтгәрәев